ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «ЛЕНИНОГОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»

«ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

14.11.2022 г.Лениногорск № 1164

Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 7 июлендәге 630 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә сөт эшкәртү чыгымнары өлешен каплауга Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 1666 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2021 елның 7 июлендәге 630 номерлы карары белән расланган «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә сөт эшкәртү чыгымнары өлешен каплауга Лениногорск муниципаль районы бюджетыннан авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләргә субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

4.2 пунктта:

икенче абзацта «һәм әлеге тәртипнең 1.6, 1.7 пунктларында күрсәтелгән күрсәткечләр» сүзләрен «субсидияләр һәм характеристикалар бирү» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «субсидия булып тора» сүзләреннән соң «, алынмаган керемнәрне каплау һәм (яисә) чыгымнарны каплау тәртибендә бирелә торган субсидиядән тыш» сүзләре белән тулыландырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты житәкчесенең икътисад буенча беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче З. Г. Михайлова

Л.М. Галимова
5-17-41